**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы КАРАРЫ**

**2022 елның23 декабре №75**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» 2016 елның 11 апрелендәге 23 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 01 маендагы 90-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 8 һәм 25 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 05 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә 2016 елның 11 апрелендәге 23 номерлы, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 статьяның 2 өлешендәге 11 абзацында «тиешле вазыйфаи төркемнәр» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 8 статьяга түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«7. Белгеч яки магистр дипломнары булган затлар өчен диплом биргәннән соң өч ел дәвамында муниципаль хезмәт стажына яисә муниципаль хезмәтнең әйдәп баручы вазыйфаларын биләү өчен белгечлек буенча эш стажына - муниципаль хезмәт стажының кимендә ярты елы яки белгечлек буенча бер ел эш стажына квалификация таләпләре билгеләнә.»;

1.2. 21 статьяда:

1) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ел саен төп түләүле отпуск муниципаль хезмәткәргә 30 календарь көн дәвамлылыгы белән бирелә.»;

2) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Ел саен өстәмә түләүле яллар муниципаль хезмәткәргә тиешле еллар эшләгән өчен, шулай ук федераль законнарда һәм әлеге Нигезләмәдә каралган очракларда бирелә. Тиешле еллар эшләгән өчен муниципаль хезмәткәргә еллык

өстәмә түләүле отпускның дәвамлылыгы муниципаль хезмәтнең һәр елы өчен бер календарь көн исәбеннән исәпләнә. Еллык төп түләүле отпускның һәм тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның гомуми дәвамлылыгы 40 календарь көннән арта алмый. Нормалаштырылмаган хезмәт көне билгеләнгән муниципаль хезмәткәргә нормалаштырылмаган хезмәт көне дәвамлылыгы өч календарь көнгә тигез еллык өстәмә түләүле отпуск бирелә. Нормалаштырылмаган хезмәт көне өчен еллык өстәмә түләүле отпуск, шулай ук федераль законда каралган башка очракларда бирелә торган еллык өстәмә түләүле отпусклар әлеге өлештә каралган еллык төп түләүле отпускның һәм тиешле еллар эшләгән өчен еллык өстәмә түләүле отпускның гомуми дәвамлылыгыннан тыш бирелә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Куйбышев Затоны шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы рәисе Н.Б. Ефимов**